ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяда:

а) 1 өлешнең 20 пунктында «документациясен раслау,» сүзләреннән соң «җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү,» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү.»;

2) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 26 пунктта «документациясен раслау,» сүзләреннән соң «шәһәр округы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү,» сүзләрен өстәргә;

б) «авыл хуҗалыгы» сүзләреннән соң «җитештерүен үстерү, авыл хуҗалыгы» сүзләрен өстәргә;

в) 43 пунктта «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3) $17^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19) шәһәр округы территориясе составына керә торган һәм аның административ үзәге булып тормаган торак пунктта нотариус булмаган очракта законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылуга;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20) Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы тарафыннан расланган халыкны кабул итү графигы нигезендә нотариусның халыкны кабул итүенә ярдәм күрсәтүгә.»;

4) 18 статьяның 1 өлешендәге $4^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 09 декабрь
№ 98-ТРЗ